

# ТУГАН ЯК
# РОДНОЙ КРАЙ

ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ № 12 (15) ДЕКАБРЬ 2009

## НОВОСТИ ТАТАРСКОГО МИРА

### Киңәйтелгән утырыш

11 — 13 нче декабрь көннәрендә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының 2009 ел эш нәтиҗәләре буенча киңәйтелгән утырышы узды. Анда Русия төбәкләре һәм чит илләрдән 200гә якын кеше катнашты. Җыелышта еллык хисап белән БТКның Башкарма комитеты рәисе Р.З. Закиров чыгыш ясады.

### Татар китаплары — сайта

Казанда **tatknigafund.ru** адресы буенча «Таткнигафонд» электрон милли китапханә системасы тәкъдир ителде. Проект күләмле китапханә фондларын һәм әйдәп баручы нәшриятләрне үз эченә алган. Әлеге милли сайт Татарстан президенты Минтимер Шәрипович Шәймиев ярдәме белән гамәлгә ашырылган.

Электрон китапханәдә барлыгы 1072 татар киабы урын алган. Проектны гамәлгә ашыручылар фондка һәр ике ай саен 500 яңа китап кертеп барылачак дип ышандыра.

15 миллион сум торган әлеге проектның төп максатлары: татар әдәбиятын популярлаштыру, милли мирасны сакларга ярдәм итә торган татар милли электрон китапханә ресурсын оештыру һәм үстерү. Ул татар әдәбияты белән кызыксынган кешеләрне, шул исәптән Россиянең төрле төбәкләрендә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезне Татарстанның тарихи-мәдәни мирасын һәм бүгенге тормышын яктырткан төрле басмалар белән таныштырып торачак.

### «Сандугач» — на областной сцене

Народный коллектив «Сандугач» при Наурузовском сельском Доме культуры недавно удостоился чести представлять Пономаревский район на областном уровне. Творческий коллектив выступил с вокальным номером на губернаторском концерте, приуроченном 265-летию губернии и 70-летию Оренбургской области.

Со сцены областной филармонии в исполнении наурузовских артистов прозвучала татарская песня. Им с восторгом аплодировали зрители, в том числе и высокопоставленные гости из Чувашии, Казахстана, Татарстана, Мордовии, прибывшие на празднование юбилейной даты, губернатор области, депутаты Законодательного собрания области и др.

Выбор участников концерта Пономаревским отделом культуры неслучайно выпал именно на наурузовский коллектив. В последнее время он, под руководством Лейсян Ибатуллиной, все больше заявляет о себе, подтверждая мастерство и сценический профессионализм. В 2007 году группа повысила свой статус, получив звание народного, и с тех пор вокальный коллектив продолжает повышать планку артистизма. На Межрегиональном фестивале татарской песни «Золотая осень»,прошедшем в ноябре в с.Асекееве, наурузовские певцы и танцоры вновь показали высокий уровень исполнительского мастерства.

**И.СУЛЕЙМАНОВА.**

### Активистам подписку

С 2010 года тираж нашей газеты заметно увеличится благодаря спонсорской помощи депутата Законодательного собрания области Ильдуса Давлятова. Газета придет в сельские клубы, библиотеки и школы татарских сел северо-запада нашей области. Подпиской будут награждены и активисты татарских автономий. С нового года редакции придется работать с удвоенной силой, так как планируется выпускать газету два раза в месяц. Первый номер читатели получат в середине января.

## Хуш киләсең, яңа ел!

**Хөрмәтле милләттәшләр!**

**Менә без сезнең белән тагын бер елны уңышларга ирешеп озатабыз. Мул игеннәр үстердек, мал-туарларыбыз да Аллага шөкер. Мәктәпләрдә балаларыбыз да тырышып укып, туган телебезне саклап үстерүдә укытучылары ярдәмендә отышлы нәтиҗәләргә ия булдылар. Татар мәдәнияте үстерүдә үткән елда мәгънәле зур чаралар үткәрелде.**

**Якташлар! Ата-аналарыбыз, уңган ир-егетләребез, җитез хуҗабикәләребез, балаларыбыз белән исән-имин каршы алыйк киләсе яңа елны! Бәхет, шатлык, сәламәтлек телимен барчагызга. Үз телемдә, үз җиремдә бәйрәм белән котлыйм сезне. Яңа елның Имин булсын һәрбер көне!**

**Ильдус ДАВЛЯТОВ,**
**Әсәкәй район татар милли мәдәният мөхтәрияте рәисе.**



РЕПОРТАЖ

## В ЕДИНЕНИИ И СОГЛАСИИ

Морозный декабрь встретил участников расширенного заседания Исполкома Всемирного конгресса татар обычным казанским гостеприимством. Все было четко продумано и обустроено для максимального комфорта гостей. На этом мероприятии принимали участие около 200 человек — активистов национальных организаций и общин РФ и зарубежья. С отчетом о проделанной работе выступили Председатель Исполкома ВКТ Р.З. Закиров, руководители комиссий и местных национальных организаций, активисты конгресса. Они обменялись мнениями, приняли итоговую резолюцию собрания и план работы Исполкома ВКТ на 2010 год.

В этом мероприятии приняли участие и оренбуржцы. В частности, депутат Законодательного собрания Оренбургской области Ильдус Давлятов.

В актовом зале Национально-культурного центра Казани была организована выставка прикладного искусства, как бы подчеркивающая приверженность традициям и культуре народа.

В целом же участники исполкома получили возможность обменяться мнениями и опытом. Ничем не передать единение гостей и хозяев мероприятия. Ведь здесь были представители татар, можно сказать, со всех концов мира. И всех их объединил родной язык.





**На снимке:** НКЦ приветливо распахнул двери; Председатель Исполкома ВКТ Р.Закиров и Депутат Законодательного Собрания Оренбургской области И. Давлятов обмениваются мнениями о проблемах татар Оренбуржья; выставка прикладного искусства.



АВТОНОМИЯ

# Ел азагында

Хөрмәтле милләттәшләр! Мин Әсәкәй район татар милли мәдәният мөхтәрияте башлыгы булып өч елга якын эшлим. Шушы еллар эчендә мөхтәрият төп бурыч итеп балаларда һәм яшь үсмерләрдә татар рухын уятуны үзәк эш итеп куйды. Моның өчен алдан комитет, мәдәният хезмәткәрләре, укытучылар, балалар бакчасы тәрбиячеләре белән ел башында план төзеп, төрле чаралар үткәрдек. Иң мөһим һәм зур чаралар: Татарстанның танылган язучысы, Мәскәүдә яшәүче Нәзифә Каримова белән очрашулар, аның иҗаты һәм китабы буенча фикер алышулар, безнең яшь үсмерләрдә һәм гомумән халык күңелендә зур эз калдырды. Бу очрашулар Әсәкәйдә, Колшәриптә һәм Богырысланда үткәрелде. Шулай ук татар халкының мәртәбәле шәхесе язучысы, шагыйрә Резеда Вәлиева белән мәктәпләрдә, мәдәният йортларында очрашулар булды. Чын татар язучысы кулыннан китаплар алу яшьләргә зур вакыйга булды. Бу чаралар безнең район халкы күңелендә, татар рухын уятып якты эз калдырды.

Татар рухы ничә гасырлар буенча җыр-моңга чорналган. Без бик рәхмәтле татарыбызның мәшһүр улы, моң иясе Мингол Галиевка. Мингол абый биш ел рәттендә безгә килеп «Ак хисләр» татар фестивале үткәрергә ярдәм итте. Ул безнең данлыклы жюри рәисе. «Ак хисләр» фестивале безнең үсмерләр һәм яшьләр өчен булса, аерым балалар өчен «Алтын көз» фестивален өч ел дәвамында үткәрәбез. Бу чарада балалар бакчасы һәм мәктәп укучылары катнаша.

Мөхтәрият, мәдәният хезмәткәрләре белән берлектә, татар халкының борынгы йола бәйрәмнәрен дә үткәрә. Шуларның берсе — «Нәүрүз» бәйрәме. 2008 елның «Нәүрүз» бәйрәмендә «Сөембикә» журналы хезмәткәрләре белән очрашу булып узды. Шул очрашуда 40 һәм 30 елдан артык «Сөембикә» журналын алучыларны тәбрикләү һәм бүләкләү булды. Шулай ук, халкыбызның иң яраткан бәйрәме Сабантуйлар да бездә шаулап — гөрләп уза.

Татар гөреф- гадәтләрен, телне саклап үстерүдә район мөхтәрият кыссалары гына таррак булу сәбәпле без данлыклы Гали авылы, күрше Борыслан шәһәре белән татар ассоциясе «Бердәмлек» оештырдык. Һәм бу үзенең уңай нәтиҗәләрен күрсәтте. Безнең балалар һәм мәдәният хезмәткәрләре, укытучылар бер-берсе белән уртаклашып, киңәшеп, татар мәдәнияте үстерүдә үзләренә яңа чыганаклар табалар.

«Бердәмлек бер елга якын эшләсә дә, мөһим чаралар үткәрде. Шул чараларның берсе «Тукай мирасы» дигән бәйге үткәрелде Гали авылында. Жюри рәисе булып бу бәйгегә шагыйрә Резеда Вәлиева килде һәм Тукайга багышланган ялкынлы әсәрен сөйләп тамашачыларны әсир итте. Һәм менә күптән түгел шул ук Гали авылында «Мин бит татар баласы» дигән конкурс бик уңышлы узды. Монда Самара өлкәсе авыллары һәм Әсәкәй районы авыллары катнашты. Гали авылы укытучылары зур әзерлек белән уздырды бу чараны. Балаларның матур татар теле белән мәртәбәле шагыйрьләрнең сүзләрен сәхнәдән яңгыратуы, күңелләрне бик куандырды. Гомумән безнең балалар тартылалар үзебезнң татар мәдәниятенә. Тик алар белән мәгънәле эш алып барырга кирәк. Оста итеп җырлыйлар да туган телдә, бииселәре дә килә татарча.

Бию дигәннән балаларны биергә өйрәтүнең бер чарасын таптык. Казаннан Габдулла Кариев исемендәге яшь тамашачылар театрының төп балетмейстеры Венер Хәмитов белән мастер-класслар үткәрдек Әсәкәйдә. Быел ике тапкыр үткәрдек, өченчесе җәйгә планга кертелде. Бик теләп йөриләр кечкенә балалар да, яшәүсмерләр дә.

Туган тел дәресләре авылларда предмет буларак укытыла. Әсәкәйдә факультатив рәвешендә.

Туган телне саклау, өйрәнү күбесенчә безнең үзебездән тора. Әгәр без өйдә балаларыбыз белән ана телендә сөйләшсәк, әгәр безнең укытучыларыбыз, мәдәният хезмәткәрләре, китапханәчеләр янып-көеп, татар кыйбласын саклау өстендә эшләсәләр, татар теле югалмас. Моңа мисаллар бар. Иң яңа мисал булып «Мин бит татар баласы» бәйгесендә, Подбельск авылы Самара өлкәсеннән рус мәктәбендә укыган ике кызның үзәккә үткәреп татарча шигырь сөйләүләре булды. Ә аларны өйрәтүче рус теле укытучысы, милләте белән татар. Бу инде, телне саклау үзебездән тора дигәннең зур үрнәге. Ә күпьеллык мисал безнең Әсәкәйнең «Чишмә» халык фольклор ансамбеле. Бу ансамбль совет чорында 1976 елда район мәдәният йортында оештырылып, татар мәдәниятен бик хупламаган чорларда да бирешмичә эшләп үз юлын тапты. «Чишмә» ансамбеле аша бик күп балалар һәм яшьләр татар рухын сеңдереп, татар моңын тыңлап, җырлап, матур мизгелләр кичерделәр 33 ел дәвамында. Аларның чыгышларын өлкә тамашачылары гына түгел, башка төбәк авыллар һәм шәһәрләр дә күрде. Ә хәзер «Чишмәдә» уйнап-җырлап йөргән татар кешеләре кайда гына яшәсәләр дә, аны сагынып, күңел җылысы белән искә алалар. Һәм бу татар мәдәниятен, телне саклауда, үстерүдә ансамбельнең эшләгән эшләренең нәтиҗәсе.

Яңа ел белән, хөрмәтле милләттәшләр!

**Ильдус ДАВЛЯТОВ.**

ТВОРЧЕСТВО ЮНЫХ

# МИН БИТ ТАТАР БАЛАСЫ

**Замечательное событие состоялось в один из воскресных дней начала декабря в Алькино, Похвистневского района, Самарской области. Здесь, в рамках межрегиональной Ассоциации татарских объединений прошел детский конкурс «Мин бит татар баласы». В нем приняли участие не только ребята из Похвистневского района, но и асекеевцы.**




Ребята соревновались в нескольких номинациях, в том числе в песне и танце, рассказывали стихи, испекли и привезли татарские блюда. Была проведена историческая викторина.

Они показали свои всесторонние способности и — что самое замечательное — желание учиться творчеству своего народа.





Так Алия Мамышева из Подбельска, почти не зная родного языка выучила и спела песню «Мама», причем в «подтанцовке» у нее были девушки другой национальности. Столь велика была тяга участницы к своему родному. В результате Алия была безусловным фаворитом зрительских симпатий.

Были среди учстников конкурса и совсем юные. Например Рим Кашапов, который несмотря на возраст выступил отлично.

Ну, а в общем зачете победили Гузель Латыпова из Асекеева и Гузель Латыпова из Алькино.

В заключение хочется сказать, что дорогу осилит идущий. Ассоциации нет фактически и года, а уже столько добрых дел сделано. Это и проведение детских сабантуев, и конкурс, и мастер классы, и «Золотая осень». Вот так и воспитывается среди детей любовь ко всему родному, традициям и культуре. А то, что это нужно, думаю не вызывает споров.

**На снимках:** участники конкурса на сцене; на суд жюри представлены национальные блюда; участников конкурса приветствует Расих Латыпов — председатель культурно-просветительского общества «Туган тел» села Алькино; вручение наград.



ВЕРУЮ

# ДОРОГОЙ ДУХОВНЫХ ЗНАНИЙ



**Второй год при Абдулинской мечети действует Исламская воскресная школа (медресе). Каждую субботу и воскресенье со всех концов города и сел района сюда съезжаются верующие, желающие изучить основы религии, исламской этики и морали, арабской графики, стремящиеся научиться чтению Корана…**

Занятия здесь ведут дипломированные преподаватели, окончившие несколько религиозных учебных заведений. Имам-хатыйб Абдулинской мечети Алмаз хазрат Кашапов обучался в трех образовательных учреждениях: в старейшем медресе России «Хусаиния», действующем в Оренбурге, в престижном Российском исламском институте в г. Уфе, а также в рамках российско-турецкой программы — в Стамбуле. Гумар хазрат Усманов — тоже выпускник уфимского Исламского института, имеет большой опыт преподавательской деятельности, наработанной в медресе с. Алькино Похвистневского района Самарской области.

В настоящее время на втором курсе медресе обучается 27 человек, а на первом численность учащихся составляют 35 человек, в том числе 8 детей. За партами сидят первокурсники — люди разных возрастов, но преимущественно пенсионного возраста. Вот перед нами солидный мужчина в строгом костюме с галстуком и непременной тюбетейке – это хорошо знакомый нам и многим абдулинцам житель с. Новоякупово и видный человек в районе Г.Ханнанов, некогда возглавлявший колхоз им. Ленина, а также работавший в ЗАО «Алина». Ныне Гумар Гараевич находится на заслуженном отдыхе, но попрежнему является человеком активной жизненной позиции, а применение своим знаниям и неиссякаемой энергии нашел в общественной деятельности, возглавив по просьбе односельчан духовное общество мусульман с. Новоякупово.

Даже на перемене продолжает старательно зубрить буквы другой пожилой человек. Не сложно определить, что в медресе он — явно самый старший ученик. Подходим к нему знакомиться. Аксакал с удовольствием вступает в беседу и представляется:

— Я — Ахмадуллин Гайса из Тирис-Усманова. Моих односельчан здесь обучается 7 человек: 3 мужчин и 4 женщин. Каждую неделю мы приезжаем на занятия в Абдулинскую мечеть на двух легковых автомобилях...

Выяснилось, что наш почтенный собеседник с недавних пор является сельским муллой. Новая стезя потребовала новых знаний. Ведь Гайса-абый до сих пор знал только те молитвы и суры из Корана, которым его научили в детстве, как в те далекие годы было принято учить любого ребенка в мусульманской семье.

— Сколько Вам лет? — интересуемся мы.

— 18, — озорно смеется дед. — Только в перевернутом виде.



Не зря говорят: век живи — век учись. Уважаемый аксакал старательно изучает арабский алфавит. Конечно, священная книга издается на татарском, русском, английском и многих других языках. Но, как пояснил имам-хатыйб А.Кашапов, на арабском языке одна и та же буква может иметь до трех вариантов произношения, поэтому правильно читать Коран может только тот, кто владеет языком оригинала — тем, на котором написана священная книга, ниспосланная Всевышним.

Наблюдая за занятиями, невольно вспоминаешь татарскую пословицу, утверждающую, что учиться — все равно, что как иголкой колодец копать: занятие столь же длительное, трудоемкое, требующее упорства, настойчивости, огромного непоколебимого желания. Особенно эта истина актуальна в случае с медресе. Арабский язык входит в тройку сложнейших в мире, и не только из-за указанных выше особенностей фонетики. Как известно, каждая буква арабского алфавита еще и на письме обозначается тремя знаками: в начале слова — одним, в середине — другим, в конце — третьим.

— Тяжело усваивается? — сопереживающе спрашивает преподаватель медресе Гумар хазрат Усманов у пожилой женщины.

— Да, — тяжело вздохнув, честно признается она.

— Если у Вас трудности в освоении учебного материала или что-либо непонятно, не стесняйтесь подойти и спросить. И ни в коем случае не бросайте учебу, рассудив, что Вам учеба не под силу: это шайтан пытается сбить нас с верного пути. Мы вам во всем поможем. Там, где мы не успеем, что-то подскажут второкурсники: они уже свободно читают Коран...

А в соседней комнате в то же самое время занимаются ребятишки в возрасте 9-14 лет. В этот день с ребятами занимается учительница И. Юнусова — она проводит повторение и закрепление пройденного материала. Речь идет о пророках, столпах, на которых зиждется ислам... Касаясь темы харама (запрещенных правоверному мусульманину деяний), учительница подробно останавливается на наиболее часто встречаемом в жизни примере — употреблении спиртных напитков, рассказывая как это пагубная привычка рушит организм и укорачивает жизнь человека.

— Наш язык не должен говорить нехороших слов, а ушки не должны слышать, когда их произносят другие; глаза наши не должны видеть то плохое, что нам иногда встречается в жизненном пути, — говорит Индира апа. — Научитесь воспринимать только позитив, брать из окружающего нас мира только добрые примеры и учиться им.

Ребята слушают ее, внимая каждому слову. А затем оживленно делятся своими знаниями, личными наблюдениями и примерами из жизни.

Когда преподавательница упоминает судный день, за партами наблюдается лес рук.

— Да, мы знаем, это произойдет в 2012-м году, 21 декабря! — насмотревшиеся телевизора дети сражают наповал «глубокими знаниями».

— Ребята, не надо верить в такие утверждения, — улыбается учительница. — Один Всевышний знает, когда и как это произойдет.

На перемене мы беседуем с ребятами. Мои предположения, что детей в мечеть приводят бабушки и дедушки, а уж в крайнем случае — родители, оказались в корне неверными.

— Я увидел объявление в газете о наборе учащихся в медресе и попросил у родителей разрешения посещать занятия. Они меня поддержали, — рассказывает учащийся 6-го кадетского класса абдулинской СОШ №3 Рустам Гусейнов.

— А я за папу молился, когда он экзамен сдавал на водительские права, — воодушевленно, с гордостью рассказывает пятиклассник-кадет той же школы Ильнас Сафин, а потом, опустив глаза, виновато добавляет: — А в следующий раз, когда он сдавал экзамен, я пошел в гости к двоюродному брату и забыл дома молитвенник... И папа не сдал экзамен.

Ильназа, как и третьеклассника из их школы Алика Хабибуллина, в медресе привел тот же Рустам. А вот пятиклассник городской СОШ №38 Ильмир Талипов ходит на занятия вместе с мамой.

По завершению занятий преподаватели и ученики дружно собираются за столом, обставленным принесенными ими же домашней выпечкой и сладостями. За чашечкой чая завязывается непринужденная беседа. Преподаватель Гумар-хазрат делится планами: с будущего года им хотелось бы организовать хотя бы двухнедельный летний лагерь для детишек.

Пока пьют чай, наступает время очередного намаза. Хазрат приглашает всех на коллективную молитву. «Я пока еще не умею», — стесняясь, произносит пожилая женщина-первокурсница. «Ничего страшного, научитесь — успокаивают ее остальные. — А пока встаньте рядом с нами и делайте то же, что и мы, читайте те молитвы, которые знаете».

Так в стенах мечети незаметно пролетают три часа. Домой верующие расходятся, с чувством умиротворения, с радостью проделывая каждый шаг по дороге духовных знаний.

**Зиля ЗАРИПОВА.**
**г. Абдулино.**

**На снимках:** муэдзин Абдулинской мечети Гумар хазрат Усманов ведет урок; юные учащиеся медресе.


## «ТУГАН ЯК» — ГАЗЕТА ТВОЕГО РОДНОГО КРАЯ!

Продолжается подписка на татарскую культурно-просветительскую газету северо-запада Оренбургской области «Туган як. Родной край» на первое полугодие 2010 года.

Газета распространяется в Асекеевском, Бугурусланском, Абдулинском, Северном, Матвеевском и Пономаревском районах. Материалы публикуются на татарском и русском языках.

Концепция редакции — издание народной газеты, отвечающей пожеланиям жителей малых городов и сел.

## ДҮРТ СӘБӘП «ТУГАН ЯККА» ЯЗЫЛЫРГА!

1. Үзегез һәм якташларыгыз, бөтен татар дөньясы, курше районнар тормышы турында хәбәрләр укыйсыз.
2. Халкыбызның гөреф-гадәтләрен дин кануннарын өйрәнә аласыз, намаз вакыты күрсәтелә.
3. Үзегез язган теләкләрне, кинәшләрне, шигырьләрегезне, хикәяләрегезне бастыра аласыз.
4. Татар халык ризыкларын әзерләргә өйрәнәсез.

**Стоимость подписки: 94 рубля 50 копеек — на 6 месяцев.**

Подписной индекс 53167. Оформить подписку можно в любом почтовом отделении или у почтальонов. Лучшие работники связи будут поощрены материально. На газету также можно подписаться с доставкой со следующего месяца. **СПРАВКИ ПО ТЕЛЕФОНУ РЕДАКЦИИ: 8-(353 51) 2 22 81.**



Солтанголның иң уңган егете, үзебезнең яраткан депутатыбыз Илдус Ядкәр улы Дәүләтовның гомер бәйрәме юбилей уңаеннан тәбрик итәбез.

Солтанголда яши безнең
Депутатыбыз Илдус.
Үзе ягымлы, сөйкемле,
Бар халык белән ул дус.

Якты акыл, саф күңел белән
Яшәү дәрте белән ул яши,
Баскан җирдән ут чыгарып
Яшен булып яшьни.

Хөрмәт иясе син, юбилеең белән,
Ир уртасы, дөнья терәге.
Кабул итеп алчы бәйрәмеңдә
Дусларыңның кайнар теләген.

Пар канатлы булып гомер кичер,
Язмыш сине ялгыз итмәсен.
Бәхет чишмәләрең тулып аксын
Чылтырап аккан суы кипмәсен.

Йортың тыныч булсын, табыннарың
Сый хөрмәттән сыгылып торсыннар.
Җанкисәгең белән балаларың
Бәхет шатлыклардан уңсыннар.

Тигезлектә яшә, исәнлек белән,
Озын булсын синең гомерең,
Тормыш дәрьяларын кичәр өчен
Ходай сиңа бетмәс көч бирсен.

**Нурзимә ГИЗЕТДИНОВА.**
**Әсәкәй авылы.**

**Безнең иң якын, иң яраткан кешебез Фәрит Хәйрулла улы Яппаровка 2010 елның башында 60 яшь тула. Без аңа исәнлек-саулык, аякта, күздә һәм акыллы башта тагы шул хәтле безне куандырып яшәүен телибез.**

**Котлаулар белән тормыш иптәше Рәсимә, уллары Фәрхәт, Рифат, киленнәре Динә белән Динара, оныгы Руслан һәм кода-кодагыйлары Байбековлар, Мингуловлар.**

**Фәритнең җылы канаты астында 38 ел гомер кичердем. Шушы шигри юллар аның 60 яшенә котлау булсын:**

Уйламадым, көтмәдем
Хыялымда йөртмәдем.
Шундый бәхет килер диеп
Уема да кертмәдем.

Рәхмәт сиңа, Фәриткәем
Әдәп-тәртип белгәнгә
Мине җирнең йөзендә
Иң бөек дип күргәнгә.

Гомер озын, кайчак ачы
Күп булгандыр чым-чыкыр.
Инде бар да үз урынында
Тәртип, Аллага шөкер.

Эчми, тартмый 60 ка
Җиттең бит син дә Фәрит.
Гаиләгә тәртип салу-
Ул үзе авторитет.

Исәнлек тә бирсен Ходай
Өстәлдә булсын барлык.
Бирсен ходай озын гомер
Хәерле, тигез картлык.

Дөньялар да имин торсын
Гөрләп барсын эшебез.
Исән-сау бул, озак яшә
Иң кадерле кешебез!

## ТАТАР ХАЛЫК АШЛАРЫ



### Итле гөбәдия

Камырны табадан чыгып торырлык итеп җәяләр дә майлы табага салалар, өстен майлыйлар. Камыр өстенә (камыр корт салгач җебеп китмәсен дип) юка гына итеп — дөге, аннары корт, аның өстенә — 2 -3 мм тигезләп дөге өстенә 6-8 мм калынлыгында ит тарткычтан чыгарган кыздырган ит салалар, иткә майда кыздырган суган кушып болгатырга мөмкин. Ит өстенә — юка гына итеп тагын бүрттергән дөге, аның өстенә вак кына тураган йомырка һәм дөге салалар. Өскә йомшарткан йөзем (күрәгә, төше алынган кара җимеш яисә өрек) салына, эченә бик күп итеп эреткән атланмай яисә сары май сибәләр.

Аннары гөбәдиянең өстенә юка гына итеп җәйгән камыр каплыйлар, кырыйларын табадагы камыр чите белән сырлап, чеметеп ябыштыралар. Гөбәдияне мичкә тыкканчы өстен майлыйлар һәм валчык сибәләр. Уртача кызулыктагы мичтә гөбәдия 40-50 минут пешә. Әзер гөбәдияне кисәкләргә бүлеп, кайнар килеш чыгаралар.

Итле гөбәдияне кортсыз гына да пешерәләр.

Уртача зурлыктагы 2,5 кг лы гөбәдиягә: 750-800 г. камыр, 250-300 г. әзер корт, 1-1,1 кг. бүрттергән дөге. 400-500 г. кыздырган ит, 100 г. кыздырган суган, 6-8 йомырка, 200 г. йөзем яисә башка җиләк-җимеш, 300-350 г. атланмай яки сары май, таба майлау өчен 50 г. май.

## ТАТАРЧА АНЕКДОТЛАР

— Бабай, начарлыкка һәрвакыт яхшылык белән җавап бирергә кирәк, әйеме?

— Әйе, балам, бик дөрес әйтәсең.

— Алайса миңа туңдырма алып бир инде, чөнки мин, өстенә басып, күзлегеңне ваттым.

* * *

Ике тычкан каймак салынган кувшинга төшә. Берсе, язмышка буйсынып, батып үлә. Икенчесе бертуктаусыз тыпырчына торгач каймакны майга әверелдерә һәм, сикереп, ирекка чыга. Моннан нинди нәтиҗә ясыйбыз? Нәтиҗә шул: теге майны ашап бетергәндә хуҗабикә савыт төбендә ике түгел, бер генә тычкан үләксәсе күрә.

* * *

Казан кешесе — башкалабызга килгән кунакка:

— Сез Казан кешесе түгелдер ахрысы?

— Каян белдегез?

— Йөзегез таныш түгел чөнки.

* * *

Бер хатын ахирәтенә үзенең ире турында сөйли:

— Мин аны 20 дә очраттым, ә 23 тә ташлап киттем.

— Әйбәт булган. Өч сәгать вакыт аз түгел инде ул.

## НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

(время местное)



| ГЫЙНВАР | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Өйлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 8-46 | 9-46 | 14-10 | 15-25 | 17-25 | 18-55 |
| 2 | 8-46 | 9-46 | 14-10 | 15-26 | 17-26 | 18-56 |
| 3 | 8-46 | 9-46 | 14-10 | 15-27 | 17-27 | 18-57 |
| 4 | 8-46 | 9-46 | 14-10 | 15-28 | 17-28 | 18-58 |
| 5 | 8-46 | 9-46 | 14-10 | 15-29 | 17-29 | 18-59 |
| 6 | 8-45 | 9-45 | 14-10 | 15-33 | 17-31 | 19-01 |
| 7 | 8-45 | 9-45 | 14-10 | 15-32 | 17-32 | 19-02 |
| 8 | 8-45 | 9-45 | 14-10 | 15-33 | 17-33 | 19-03 |
| 9 | 8-44 | 9-44 | 14-10 | 15-34 | 17-34 | 19-04 |
| 10 | 8-43 | 9-43 | 14-10 | 15-36 | 17-36 | 19-06 |
| 11 | 8-42 | 9-42 | 14-10 | 15-38 | 17-38 | 19-08 |
| 12 | 8-41 | 9-41 | 14-10 | 15-39 | 17-39 | 19-09 |
| 13 | 8-40 | 9-40 | 14-10 | 15-40 | 17-40 | 19-10 |
| 14 | 8-39 | 9-39 | 14-10 | 15-42 | 17-44 | 19-12 |
| 15 | 8-38 | 9-38 | 14-10 | 15-44 | 17-46 | 19-14 |
| 16 | 8-37 | 9-37 | 14-10 | 15-46 | 17-48 | 19-16 |
| 17 | 8-36 | 9-36 | 14-10 | 15-48 | 17-50 | 19-18 |
| 18 | 8-35 | 9-35 | 14-10 | 15-50 | 17-52 | 19-20 |
| 19 | 8-34 | 9-34 | 14-10 | 15-52 | 17-54 | 19-22 |
| 20 | 8-33 | 9-33 | 14-10 | 15-54 | 17-55 | 19-24 |
| 21 | 8-32 | 9-32 | 14-10 | 15-55 | 17-56 | 19-25 |
| 22 | 8-31 | 9-31 | 14-10 | 15-56 | 17-58 | 19-26 |
| 23 | 8-30 | 9-30 | 14-10 | 15-58 | 18-00 | 19-28 |
| 24 | 8-29 | 9-29 | 14-10 | 16-00 | 18-02 | 19-30 |
| 25 | 8-27 | 9-27 | 14-10 | 16-02 | 18-04 | 19-32 |
| 26 | 8-25 | 9-25 | 14-10 | 16-04 | 18-05 | 19-34 |
| 27 | 8-23 | 9-23 | 14-10 | 16-06 | 18-08 | 19-36 |
| 28 | 8-22 | 9-22 | 14-10 | 16-08 | 18-10 | 19-38 |
| 29 | 8-21 | 9-21 | 14-10 | 16-10 | 18-12 | 19-40 |
| 30 | 8-20 | 9-20 | 14-10 | 16-12 | 18-14 | 19-42 |
| 31 | 8-18 | 9-18 | 14-10 | 16-14 | 18-14 | 19-44 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом. Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут.**

ТУГАН ЯК
РОДНОЙ КРАЙ
E-MAIL: tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

**УЧРЕДИТЕЛЬ:** ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:** С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском, Северном районах.
Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

Газета отпечатана в Бугурусланской типографии. 461600, г. Бугуруслан, ул. Революционная, 14.
Цена свободная. ТИРАЖ: 2000 ЭКЗ.

Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ